# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Гражданнарның сәламәтлеген саклау турында"**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 9 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

"Гражданнарның сәламәтлеген саклау турында" 1998 елның 18 июнендәге 1659 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (I өлеш); 2003, № 5; 2004, № 3 (I өлеш); 2006, № 3 (I өлеш); 2007, № 12 (II өлеш); 2009, № 7-8 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) түбәндәге эчтәлекле $16^1$ статья өстәргә:

"$16^1$ статья. **Беренче ярдәм күрсәтү**

Беренче ярдәм Россия Федерациясе гражданнарына һәм аның территориясендәге башка затларга бәхетсезлек очракларында, имгәнүләр, агуланулар вакытларында һәм аларның гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч яный торган башка халәтләрдә һәм авырулар вакытларында закон буенча яисә махсус кагыйдә буенча беренче ярдәмне күрсәтергә тиешле һәм тиешле әзерлеге булган затлар (Россия Федерациясе эчке эшләр органнары хезмәткәрләре, Янгынга каршы дәүләт хезмәте хезмәткәрләре, хәрби хезмәткәрләре һәм анда эшләүчеләр, һәлакәттән коткару формированиеләренең һәм һәлакәттән коткару хезмәтләренең коткаручылары, транспорт чараларын йөртүчеләр һәм башка затлар) тарафыннан күрсәтелә.

Беренче ярдәм күрсәтү буенча уку-укыту курсының, предметының, дисциплинасының якынча программалары, шулай ук беренче ярдәм күрсәтү

чаралары исемлеге сәламәтлек саклау өлкәсендә норматив-хокукый җайга салуны гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан әзерләнә.";

2) 17 статьяның сигезенче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Гражданнар үзләре тирәсендәге затларның йогышлы авыруы аркасында эштән читләштергән очрактагы карантин вакытында, мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенә йөрүче 7 яшькә кадәрге баласының яисә билгеләнгән тәртиптә хезмәткә яраксыз дип танылган башка гаилә әгъзасының карантины очрагында хезмәткә вакытлыча сәләтсезлек пособиесенә федераль закон нигезендә хокуклы.";

3) 21 статьяның өченче һәм дүртенче өлешләрен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Ата-ананың берәрсенә (башка законлы вәкилгә) яисә гаиләнең башка әгъзасына баланы дәвалау мәнфәгатьләрендә бала сырхауханә учреждениесендә булган барлык вакыт эчендә баланың яшенә бәйсез рәвештә бала белән бергә булу хокукы бирелә.

Гаиләнең авыру әгъзасын караганда кирәк чакта вакытлыча хезмәткә сәләтсезлек пособиесе федераль закон нигезендә түләнә.";

4) 38 статьяның беренче өлешендә ", шулай ук аны беренче ярдәм рәвешендә закон буенча яисә махсус кагыйдә буенча күрсәтергә тиешле затлар тарафыннан" сүзләрен төшереп калдырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2010 елның 29 июне
№ 37-ТРЗ